**№1 (258)** Гыйнвар 2017 / Рабигыль-ахыр – Җөмәдәл-әүвәл 1438

# دين و معيشت

اورنبورغ ايچون سنه‌لك بهاسى ٥ صوم يارم سنه‌لكى ٢ صوم ٥٠ تين، اوچ آيلغى ١ صوم ٢٥ تين، بر آيلق ٥٠ تين، چيت شهرلركه سنه‌لك بهاسى ٦ صوم آلتى آيلق ٣ صوم اوچ آيلق ١ صوم ٥٠ تين بر آيلق ٥٠ تين.

Адресъ: г. Оренбургъ, редакція журнала «Дуния ва Магишетъ», Введенская ул. д. Фишманъ. Тел. 289.

ولو لا دفاع الله الناس بعضهم ببعض لهدمت صوامع وبيع وصلوات ومساجد يذكر فيها اسم الله كثيرا ولينصرن الله من ينصره إن الله لقوي عزيز

# «ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ»КӘ - 110

## – اخطار –

ژورنال چيقاروب طاراتودن مقصودمز ملتمز آراسنده بيك طارالغان اعتقاد و هم خلق بزوقلقلرينه هم تربيه‌سزلكلركه قولمزدن كلكان قدر دارو ايزلاب اوزمزننك امام اغظم مذهبى‌نك اعتقاد و اخلاق و فقه كتابلرندن قاراب طابقان دارولرمزنى يازوب بيكراكده عوام خلقمزنى آكاهلندرمق بولغانغه كوره مذكور خلق‌ننك اوتنووى بوينچه ژورنالمزنى عوام تيلى ايله يازارغه نيتلنوب اوشبو اخطارنامه‌مزنى يازدق

Журнал чыгарып таратудан максудымыз милләтемез арасында бик таралган игътикад вә һәм халык бозыклыкларына һәм тәрбиясезлекләргә кулымыздан килгән кадәр дару эзләп, үземезнең Имам Әгъзам мәзһәбенең игътикад вә әхлак вә фикһ китапларыннан карап тапкан даруларымызны язып, бигрәк тә гавам халкымызны агяһләндермәк булганга күрә, мәзкүр халыкның үтенүе буенча журналымызны гавам теле илә язарга ниятләнеп, ошбу ихтарнамәмезне яздык.

١١٠ يل ئلك، ١٩٠٦ يلنڭ ٣١ ديكابرنده اورنبورغ شهرنده «دُنيه و معيشت»نڭ ١ نچىُ سانئ دُنيه كوره. كيله‌چه‌كته «دين و معيشت» ديب آتالا باشلاياچاق بو دينى ژورنال چاغشترماچه آوزن عمرلىُ بولا - اول ١٢ يل دوامنده چغوب كيله. آنئڭ نشيرىُ - بيلگلىُ تاتار حَيريه‌چيُسىُ اوغلئ، مللا، سوداگر محمد ولى عبدالولى اوغلئ حُسينوف بولا. قدمچيُله‌ر تارافندن چغارلغان بو ژورنال شاقتى وقت بارئ تيسكه‌رىُ گنه به‌يه‌له‌نه. بوكونگىُ كوُنده ايسه بز انڭ ئوز ئوُستنلكلريُنه، اونغاي ياقلارئنه ده اعتبار بيرمي قالورغه تييش توگل. اول ده بيت - وقتلئ مطبوعاتبز صحيفه‌لرنڭ برسىُ. گازيتابزنڭ آلگئ ساننده «دين و معيشت» ژورنالنڭ تاريخنه باغشلانغان، آصلئ به‌يه‌له‌ونىُ مقصد ايتوب قويغان مقاله‌لر اورن آلدئ.

(дәвамы 2 нче биттә)

# «Дин вә мәгыйшәт»кә – 110




XX йөз башы – милләтебез, өммәтебез, мәгарифебез тарихында бик үзенчәлекле, үзгәрешләргә бай һәм мәшһүр руханиларыбыз, язучыларыбыз, мәгърифәтчеләребез яшәгән чор.

Нәкъ шушы вакытта Россия татарлары үз вакытлы матбугатын булдыруга ирешә. Шактый газета-журналларда дини вәзгыять тә яктыртыла торган була. 110 ел элек, 1906 елның 31 декабрендә Оренбург шәһәрендә «Дөнья вә мәгыйшәт»нең беренче саны дөнья күрә. Киләчәктә «Дин вә мәгыйшәт» дип атала башлаячак әлеге дини журнал чагыштырмача озын гомерле була – ул 12 ел дәвамында чыгып килә. Аның нәшире – билгеле татар хәйриячесе улы, мулла, сәүдәгәр Мөхәммәтвәли Габделгани улы Хөсәенов була. Кадимчеләр тарафыннан чыгарылган бу журнал шактый вакыт бары тискәре генә бәяләнә. Бүгенге көндә исә без аның үз өстенлекләренә, уңай якларына да игътибар бирми калырга тиеш түгел. Ул да бит – вакытлы матбугатыбыз сәхифәләренең берсе. Газетабызның әлеге санында «Дин вә мәгыйшәт» журналының тарихына багышланган, асылын бәяләүне максат итеп куйган мәкаләләр урын алды.

1993 елдан Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең газетасы чыга башлый. Газетабызның максатыннан, эчтәлегеннән, асылыннан чыгып, ул да «Дин вә мәгыйшәт» дип аталды. Ягъни басма һәм дини, һәм дөньяви мәсьәләләрне яктырта. Интернет заманында, күптөрле мәгълүматка юллар ачылган вакытта, ялгыш дини фиркалар таралганда, укучыларга ышанычлы мәгълүмат һәм хәбәрләр тапшыру актуаль булып тора.

«Дин вә мәгыйшәт» беренче чиратта укучыларыбызга Мөхәммәд Пәйгамбәребез ﷺ сөннәтен аңлатырга, үгет-нәсыйхәт бирергә, кардәшләребезнең рухи байлыгын куәтләргә, дини, тарихи, әдәби мирасыбызга караган мәгълүматларны җиткерергә, Диния нәзарәте эшчәнлеге, Республикабыз һәм мәхәллә яңалыклары белән таныштырып барырга юнәлтелгән.

**Камил хәзрәт Сәмигуллин,**
**Татарстан Республикасы**
**мөселманнарының Диния**
**нәзарәте рәисе, мөфти,**
**«Дин вә мәгыйшәт»**
**газетасының баш мөхәррире**

# Заман чаткысы

Егерменче гасыр башы. Татар дөньясының кайнаган, социаль, сәяси һәм милли уяну кичергән, яңарышка, алгарышка томырылган чоры. Табигый, төрле кыйблалы сәяси, милли, дини хәрәкәтләрнең калкып чыгуы, аларның бер-берсе белән көрәше, бәрелеше хас бу чорга. Россиянең татарлар яшәгән күпсанлы төбәкләрендә шушы халәтне чагылдырган дистәләрчә яңа газета-журналлар ачыла, китаплар басыла, аларны нәшер итүче зур типографияләр барлыкка килә. Бу исә, үз чиратында, туып килүче давыллы-фаҗигале гасырда татар иҗтимагый фикерен хәзерләүдә, аны чарлауда, сафландыруда һәм ныгытуда, татар халкының милли үзаңын формалаштыруда искиткеч зур роль уйнаган.

Ул чор татар мәдәниятенең иң зур үзәкләреннән берсе булган Оренбург та бу хәрәкәттән читтә калмаган. Танылган татар китабы белгече Әбрар Кәримуллин мәгълүматларына караганда, XX гасыр башында биредә 400гә якын татар китабы басылган, аларның гомуми тиражы бер миллион данәгә җиткән. Шушында ук «Вакыт», «Шура», «Кармак», «Мөгаллим», «Чүкеч», «Яз», «Урал» һәм башка шундый газета-журналлар нәшер ителеп килгән.

«Дин вә мәгыйшәт» журналы шушы уяну дулкынында Оренбургта дөньяга килгән даими басмаларның берсе һәм иң озын гомерлесе. Ул 1906 елның декабреннән 1918 елның язына кадәр айга дүрт мәртәбә 16 биттә чыгып килгән. Нәшире билгеле татар хәйриячесе, иганәчесе Гани Хөсәеновның улы Мөхәммәтвәли Хөсәенов, мөхәррире Заһидулла Хәйруллин, соңрак Фәезхан Даутов булган. Коммунистик идеология хакимлеге дәвамында журнал кадимчелек һәм карагруһлык коралы дип кенә каралып бәяләнде. Мәсәлән, шул ук Ә. Кәримуллин «Китап дөньясына сәяхәт» китабында болай дип яза: «Татар демократик китабына, татарлар арасында барган социаль һәм милли уянуга каршы көрәш йөзеннән 1906 елда Оренбургта карагруһ дин әһелләре «Дин вә мәгыйшәт» дигән журнал чыгара башлыйлар, шуны бастыру өчен типография оештырып, анда китаплар да чыгару эшенә керешәләр» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1979). Атаклы әдәбият һәм матбугат белгече, язучы Исмәгыйль Рәмиев «Татар вакытлы матбугаты (1905–1925)» китабында «Дин вә мәгыйшәт»кә тагын да карарак бәяләмә бирә: «Бу журнал – карагруһлык, искелек, кадимлек, һәр яңага каршы килүчәнлек, иң әшәке клерикаль. Үзенең мәсләге, бөтене белән, ул мөселман погромщикларының нәшере булып барды» (Казан, Гяжур басмасы, 1926).

Әмма журналның шушы катлаулы һәм буталчык, төрле идеяләр һәм фикерләр көрәше чорында барлыкка килүе бик тә табигый һәм аның халкыбызның иҗтимагый фикерен чарлаудагы роле бәхәссез. Октябрь инкыйлабына кадәр нәшер ителгән басмалар арасында иң озын гомерле булуы да, киң таралуы да нәкъ менә шул хакта сөйли.

Журнал 14 нче санга кадәр (бер елдан артык чорда) «Дөнья вә мәгыйшәт» исеме белән чыга. 1906 елның 31 декабрендә чыккан беренче санында ук журналның эчтәлеге, асылы, максатлары билгеләнә һәм 17 пункттан торган киң программасы тәкъдим ителә. Программа дини һәм дөньяви хәят мәсьәләләрен дә, ислам милләтләренә кагылышлы мәгълүматларны да, сәяси, сәүдә, милли, рухи мәсьәләләрне дә, авыллар һәм шәһәрләр тормышын да, хөкүмәт, Дума эшчәнлеген дә, бәйге, җыен, бәйрәм хәлләрен дә киң яктыртып барачагын, әдәби әсәрләр бастырачагын вәгъдә итә, сорауларга җавап бирәчәген белдерә, һәр санның соңгы битләрендә күпкырлы һәм кызыклы «Оренбург хәбәрләре»н биреп бара. Күренә ки, журнал тормыш-яшәешнең бик күп өлкәләрен үз эченә алган һәм алардан шактый бай мәгълүмат биреп баручы матбугат чарасы булып торган. Ә иң мөһиме, басманың шушы күпкырлы программасы, шуңа нигезләнгән бай эчтәлеге аның үзенең беренчел һәм төп максатына ирешүдә – җәмгыятьтә диннең һәм яшәешнең «алтын урталыкта» булып яшәүләрен югалтмас өчен хезмәт итүдә гаять зур әһәмияткә ия булган. Димәк, журналны берьяклап кына каралап тамгалау, һичшиксез, хакыйкатькә хилафлык кылу булыр иде.

Әмма үзенең асыл максатларыннан берсе итеп Ислам динен пропагандалауны, аның сафлыгын саклауны билгеләгән «Дин вә мәгыйшәт» яңарыш чорына хас булган диннән бизү, аннан читләшү, Ислам динен кимсетү һәм мәсхәрәләү көрәшләренә битараф кала алмаган. Шушы нигездә ул җәдитчеләр белән кискен бәхәскә керә. «Мәхәллә имамнарын сүгә-сүгә мәхәллә халкы белән алар арасына дошманлык салып, галимнәр белән халык арасына суыклык төшереп, халыкка әйткән нәсыйхәт вә вәгазьләрнең тәэсирен бетереп, дин турында сөйләгән вакытта гавамны ишетмәслек һәм ишетсә дә голәмә сүзен тотмаслык дәрәҗәгә китерделәр», дип гаепли журнал җәдитчеләрне («Дөнья вә мәгыйшәт», 1907, № 9). Һәм халыкны дингә, ислам юлына чакыра: «Әй мөселман җәмәгате! Сезгә вә безгә иң әүвәл дин кирәк. Дин безне бетмәс-төкәнмәс, очы-кырые юк бер сәгадәткә, изгелеккә, рәхәткә

ирештерә торган нәрсәдер, динсезлек исә бетмәс-төкәнмәс, очырые юк җәһәннәм газабына алып барадыр» («Дин вә мәгыйшәт», 1907, № 14).

Журнал битләрендә җәдитчеләрнең әрсезлеге һәм кайбер бозыклыклары фаш ителеп язылган мәкаләләрне күпләп укырга мөмкин. Билгеле, алар һич тә урынсыз булмаган, чөнки яңарыш-алгарыш чоры халыкның аңын уяту, аның җәмәгать активлыгын үстерү белән беррәттән, аның тормышына төрле бозыклыклар, әхлаксызлык чалымнары үтеп керүенә дә китергән. Мондый хәл татар дөньясын да читләтеп узмый. Бер мәкаләдә Эстәрлетамак шәһәреннән 55 хатын-кыз имзалаган һәм Дума депутаты Шәрәфетдин Мәхмүдовка юлланган үтенеч-зар хаты ките-релә. Монда алар үз ирләрен һәм улларын эчкечелектә гаеплиләр, үзләренә һәм балаларына игътибар калмавына зар елыйлар, ахыр чиктә, депутаттан шушы ямьсез гадәтләрне киметүдә, бетерүдә ярдәм сорыйлар («Дин вә мәгыйшәт», 1908, № 11).

Шушы борчулы сорауларга чаң сугып, бу әхлаксызлыкларны бетерүнең төп юлы итеп динне атап, журнал үз язмаларында ислам тәрбиясен ныгытуга өнди. Дөрес, бу инде «Дин вә мәгыйшәт»нең мәсьәләне берьяклы, тар күзаллавын да дәлилли. Асылда, мондый халәтнең нигезендә ул чорда хәерчелектә, изелүдә яшәгән татар халкының тормышы авырлыгы, киләчәккә ышанычы сүнүе, өметсезлеккә бирелүе яткан. Кадимчеләрнең идеологик дошманнары булган җәдитчеләрнең үзләренең дә теләге халыкны нәкъ менә шул халәттән чыгу юлларын эзләүгә, яктылыкка омтылуга өндәү булган бит. Шушы максаттан, җәдитчеләр игътибарларын яшьләргә, мәдрәсә, уку йортлары шәкертләренә юнәлткәннәр, чөнки алар халкыбызны мәгърифәт юлына чыгаруда нәкъ менә яшьләрнең төп роль уйнаячагын яхшы аңлаганнар. Шул ук максатка омтылган, әмма җәмгыять әхлагын сафландыру чарасын бары тик динне ныгытуда күргән «Дин вә мәгыйшәт»нең җәдитчеләр белән төп бәрелешләре дә шушы юнәлештә аеруча кискен чагыла.

Чор рухына бәйле рәвештә бу елларда мәдрәсә һәм мәктәпләрнең уку-укыту программаларын яңарту, ислах итү, аларга дөньяви фәннәрне киңрәк кертү мәсьәләсе киң бәхәс нигезе булып әверелә. «Дин вә мәгыйшәт» тә беренче саныннан бу мәсьәләне үзенең игътибар даирәсенә ала. Бу җәһәттән беренче санда басылган «Ислах мәкатиб вә мәдарис» («Уку йортларын һәм мәктәпләрне үзгәртү» – Р.М.) мәкаләсе гыйбрәтле: «...дини гыйлем өйрәнелә торган мәдрәсәләргә яңа фәннәр вә дөньяви мәгарифне кертү дини гыйлемне мөмкин кадәр киметү вә аны киметү хисабына фәннәрне вә мәгарифне арттыру тиешле булачагы ачыктыр. Бу юл белән барганда, дини гыйлемнең әһәмияте төшеп калып барылыр, һәркем фәннәр вә дөньяви мәгарифне өйрәнүгә әһәмият биреп, ахырда диннең әһәмияте бетүе бик мөмкин» («Дөнья вә мәгыйшәт», 1906, № 1). Күргәне-безчә, монда дөньяви мәгърифәтнең кирәклеген, аның котылгысызлыгын аңлау да, ахыргы тискәре нәтиҗәләре өчен борчылу да ярылып ята.

«Дин вә мәгыйшәт» татар теле язмышына янаган фаҗигане дә иң алдан күргән, аның алдагы язмышы өчен борчылып-ачынып язган. Бу җәһәттән ул кайбер җәдитчеләрнең ана теленә булган салкын мөнәсәбәтен гаепли: «... Алар аз гына укый-яза белсәләр, татар безграмотный диюдән чирканмыйлар. Икесе-өчесе бер җиргә туплансалар, татарча сөйләшергә гарьләнеп, русча сөйләшәләр. Аларга ана телен саклау шулай имеш» («Дин вә мәгыйшәт», 1908, № 6).

«Дин вә мәгыйшәт» журналында «театр» рубрикасы белән бирелгән мәкаләләр әһәмияте ягыннан дин, уку-укыту, хатын-кыз һәм башка мәсьәләләрне яктырткаңнарыннан һич кенә дә калышмаган. Аларда кадимчеләрнең бу мәсьәләгә карашы, тәкъдимнәре ачык чагыла. XX гасыр башы – татар театрының туу, беренче адымнарын ясау чоры һәм җәмгыять тормышындагы бер генә күренешкә дә игътибарсыз, битараф булып калмаган басма монда да үз позициясен ачык һәм аңлаешлы итеп әйткән, театрның үсүе, көннән-көн киңрәк таралуы турында ачынып язган. Җыеп әйткәндә, төрле саннарда басылган бу мәкаләләрнең асылы, аларның авторларының фикере бер – театр динсезлеккә, әхлаксызлыкка алып бару коралы. Иң әһәмиятлесе шунда: кадимчеләр театр тамашасының үзенә асылда каршы килмичә, аларны анда кылына торган бозыклык мисаллары (эчү, тәмәке, әфьюн тарту, хатын-кызларның әдәпсезлеге, дингә карата тупаслык, дин әһелләренең образларын бозып күрсәтү) һәм башка шундый күренешләр борчый һәм ачындыра («Дин вә мәгыйшәт», 1907, № 33; 1911, № 4; 1911, № 12).

Журналның беренче саннарыннан башлап, хатын-кызның тормыштагы, җәмгыятьтәге урыны аның игътибары үзәгендә булган. Бу мәсьәләдә аның фикере ике төрле, хәтта капма-каршы диярлек дә була. Бер яктан, басмадагы мәкаләләрдә татар хатын-кызларының авыр тормышы өчен ачыну чагыла, аның сәбәпләре күрсәтелә. Ә икенче яктан, хатын-кызлар, бигрәк тә яшьләр арасында бозыклык, әхлаксызлык, җенси тотнаксызлык күренешләренең ешаюы, хатын-кыз иреге, аның хокуклары өчен көрәшнең активлашуы мәкаләләр авторларын борчылырга мәҗбүр итә. «Мусават хокук вә хөррият ниса» («Хокуклар тигезлеге һәм хатын-кыз иреге» – Р.М.) мәкаләсендә шундый юллар бар: «Хәзерге заманда үзләренә тәрәккъый пәрвәр дип исем биргән образованныйлар хокуклар тигезлеге һәм хатын-кыз иреге мәсьәләсен уртага куйдылар. Хокуклар тигезлеге, димәк ир белән хатын арасында аерма булмыйча, иргә никадәр хокуклар бирелсә, хатынкызга да бәрабәр хокуклар бирелсен... Болай булганда хатыннарыбыз француз хатыннары кебек үзләре ирләрен әсир итәрләр» («Дин вә мәгыйшәт», 1907, № 15).

Шунысы кызык, хатын-кызның җәмгыятьтә тотарга тиешле урыны хакындагы бәхәсләрнең әле бүген дә тынганы юк. Һәм еш кына ул бәхәсләр гасыр башында кадимчеләр һәм җәдитчеләр арасындагы фикер көрәшенә аваздаш.




«Дин вә мәгыйшәт» үзендә чагылган һәм күтәрелгән мәсьәләләрне шул чорның башка агымдагы басмаларындагыча кистереп, раслап, «бердәнбер хакыйкать» итеп түгел, ә фикерләү, уйлану, киңәшү өчен нигез буларак тәкъдим иткән һәм бу аның зур бер отышы булып тора. Ул заман өчен бигрәк тә. Шушы алымы белән ул шул чор укымышлы кешеләрен, зыялыларын татар тормышының төрле яклары турында уйланырга, эзләнергә, бәхәсләшергә этәргән, димәк, татар мохитен хәрәкәтләндерүче бер чара булган. Аның тарихи кыйммәте дә кадимчелек яисә җәдитчелек таянычы булуда түгел, әнә шул үз кыйблаc ын, үз фикерен, үз алымын тапкан басма булуында.

**Тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Татарстан Республикасы законнары һәм Дәүләт Советының норматив-хокукый документлары текстларын тәрҗемә итү һәм төңгәлләштерү бүлегенең баш киңәшчесе Мөхәммәтшин Рөстәм Гарифҗан улы**

# XX гасыр башында традиционалист мөселман галимнәре һәм «Дин вә мәгыйшәт»

XX гасыр башы сәяси, мәдәни һәм мили үзгәрешләргә бай чор булды. Татар-мөселман реформаторлары (җәдитчеләр) белән мөселман традиционалистлары (кадими голәмә) арасындагы мөнәсәбәтләр заманының ачык чагылышы булып торды. Историографиядә яңарыш, алгарыш, уку-яза белүнең таралышы һәм сәяси үзаң үсүе күпчелек очракларда җәдитчеләр белән бәйләнелде. Кадимчеләрне исә тарихчылар алгарышның күләгәсендә калдырды һәм артта калган, заман тудырган таләпләрне кабул итәргә, яңалыкларга җавап бирергә сәләтсез һәм мөселман җәмгыятенең алгарышына каршы торган дип тасфирлады.

Бу хакыйкатькә туры килми. Беренчедән, традиционалист мөселман галимнәре өчен, гасырлар дәвамында урнашып килгән дини традицияләрне саклау, мөселманлыкның иминлеген кайгырту һәм аны саф килеш саклап калу төп борчу була. Икенчедән, алар гел «алгарыш»ка каршы килде дип әйтү дөрес булмас, алар динне алгарыш барышының үзәгендә күрергә теләде. Кадимчеләр фикере буенча, үзенең дини кыйммәтләрен саклаган җәмгыять кенә алгарышка ирешә ала. Алар заманча, басма технологияләр кулланган, һәм алгарыш барышында, милли үзаң һәм укыту реформасында актив катнашкан. Традиционалист мөселман галимнәре замана таләпләренә һәм үзгәрешләргә сизгер була, ләкин үзгәрешне мөселман өммәте бердәмлегенә зыян китермәгән очракта гына танырга әзер була.

Басма технологияләр традиционалист галимнәр өчен үз карашларын җиткерергә яңа мөмкинлекләр тудыра. Әлеге мөмкинлек булып алар өчен «Дин вә мәгыйшәт» журналы ачыла.

«Мөселманнар өчен дини журнал яки гәҗит булмаганлыктан, Рәсәй җирендәге 20 миллионнан артык булган мөселман җәмә-гатьчелеге күп кенә дини ихтыяҗларга мохтаҗ. Моны күз алдында тотып, «Дин вә мәгыйшәт» журналының башкарма комитеты бу ихтыяҗларны канәгатьләндерү максатыннан тәвәккәллек белән хезмәт итәргә әзер». Бу сүзләр «Дин вә мәгыйшәт» журналының беренче санындагы язылу игъланында дөнья күрә.

«Дин вә мәгыйшәт» журналында язучылык иткәннәрнең фикерләре буенча, традицион галимнәр өчен карашларын җиткерү өчен башка басма булмый, «Дин вә мәгыйшәт» аларга язарга мөмкинлек биргән бердәнбер периодик басма була. Язучы һәм укучыларның киң географиясе журналның популярлыгы һәм аудиториянең төрлелеген раслый. Басманы Идел-Урал регионы һәм Көнбатыш Себернең төрле шәһәр-авылларында укыйлар.

«Дин вә мәгыйшәт» мөселман бастыру эше таралыш алганда һәм мөһим сәяси вакыйгалар чорында (1905 елгы инкыйлаб, 17 нче октябрь манифесты, җәдидчелек вәкилләренең сәяси тормышта актив катнашуы һәм «Иттифак әл-Мөслимин» партиясе оештыру) пәйда була. Җәдитчеләр мөселман уку-укытуында, хатын-кызның җәмгыятьтәге урынын арттыруда, мөселман мәдәни тормышында радикаль реформалар яклы торган була. Җәдитчеләр үз фикерләрен «алгарыш», «прогресс» термины кысаларында билгеләи. Мөселман җәмгыятене алгарыш алдында тора, аны тормышның барлык өлкәләрендә дә тормышка ашырырга кирәк дигән карашны яклый һәм үзләренә мөселман җәмәгатьчелеген «алгарышка» таба алып бару вазыйфасын йөклиләр. Алар традиционализм тарафдарларын мөселман җәмгыятендә артта калганлыкны мәңгеләштерүдә гаепиләр.

«Дин вә мәгыйшәт» язучылары бу карашлар белән килешми. Журналның аноним бер язучысы «алгарыш» идеясы һәм мәдрәсә реформасын яңа һәм җәдичеләр яза башлаганчы бөтенләй игътибар ителмәгән дип атый. «Дин вә мәгыйшәт»нең авторлар «артта калганлык» терминының дөрес түгел һәм бары җәдидчеләр дискурсында барлыкка китерелгән дип белдерә, соңгылары исә бу төшенчәне белем бирүнең традицион системасын һәм аның тарафдарларын тәнкыйть итү өчен кулланган дигән фикердә торалар. Традиционалистларның фикере буенча, җәдитчеләрнең фикерләре «алгарыш» дип карала алмый, аларның максатлары традицион мөселман мәгарифенә, мәдрәсәләргә куркыныч яный дип белдерә.

«Дин вә мәгыйшәт» журналында «Шура», «Вакыт», «Идел», «Тәрҗеман», «Йолдыз» кебек җәдиди журналларга актив җавап кайтару башлана. Күп кенә мәкаләләр мөселман тормышының төрле яклары турында язучы галим Муса Бигиевкә каршы юнәлтелгән була. Ул кузгаткан Ислам дин белеме, хокук, хатын-кыз, риба һәм башка темалар традиционалист галимнәр арасында бәхәс күтәрә, һәм «Дин вә мәгыйшәт» журналында дөнья күрә.

Гомумән алганда, «Дин вә мәгыйшәт» басмасының зур өлеше дингә багышланган була: дини фикер һәм фикһ аспектлары, Ислам тарихы, галимнәр тормышы һәм дини белем. Калган мәкаләләр мөселманнарның сәяси эшчәнлегенә, җәдид һәм җәдиди мәдрәсәләр тирәсендәге бәхәсләр, мәдәни, социаль һәм икътисади тормыштагы үзгәрешләргә (театр, китапханәләр, кием-салым, музыка), хатын-кыз тормышы, медицина, Көнбатыш һәм башка мөселман җәмгыятьләрендәге алга китешләргә багышланган була.

Мөселман реформистлары белән традиционалист галимнәр арасында кузгалган һәм «Дин вә мәгыйшәт» битләрендә актив куертылган темаларның берсе уку-укыту системасы була. Җәдитчеләр тәкъдим иткән мәдрәсә системасындагы үзгәртеп корулар (фонетик метод, фәнне туган телдә, гарәп телен чит тел буларак өйрәнү, табигый фәннәр кертү, рус телен өйрәнү) традиционалистлар өчен кабул итәрлек булмый. Алар журнал битләрендә мәдрәсәдә белем бирүнең төп урында дин булган традицион системасын яклап чыга. Традиционалист галимнәр басма битләрендә җәдитчеләр кертергә тырышкан яңарышлар мәдрәсәдәге белем алуның традицион барышын юкка чыгара һәм дини белемгә тискәре йогынты ясый, дип нәтиҗә ясыйлар.

Традиционалистларның карашларын чагылдырган «Дин вә мәгыйшәт» авторлары өчен «җәдиди» мәдрәсәләрдә белем алучыларның дини тормыштан читләшүләре борчулы күренеш була. Мәдрәсә тиешле мөселман әхлагын тәрбияләргә тиеш, чөнки мәдрәсә җәмгыятьнең киләчәк галимнәрен һәм аны алып баручыларны тәрбияли, ди алар. «Дин вә мәгыйшәт»тә язучылар Европадагы технологик үсешләргә уңай карый һәм бу үсешләрне мөселман җәмгыяте үзләштерергә тиеш дип таба, ләкин алар Европадагы тормышның башка якларын кабул итүгә каршы була (тарту, эчү һ. б.). Дини һәм әхлакый белем бирүдәге җитешсезлекләр диннең һәм киләчәкнең бөлгенлегенә китерәчәк, ди алар басма битләрендә. Моңарда алар реформаторлар пропагандалаган яңа яшәү рәвешен һәм җәдитлек тәрбиясен гаепле дип атый.

Басмада шулай ук традицион фикһны яклаган мәкаләләр һәм мөселман җәмгыятен кызыксындырган фәтвалар дөнья күрә. «Дин вә мәгыйшәт»нең беренче саныннан башлап, «Мәсьәлә» сәхифәсе алып барыла, монда укучыларны фикһ буенча кызыксындырган сораулар һәм мөхәррирләрдән аларга җаваплар бастырыла. Соңрак «Фәтва» сәхифәсе өстәлә. Традиционалистларның максаты булып, үз хокукый фикерләрен җәдитчеләрнең газета-журналларында пәйда була торган реформистлар фикеренә каршы җиткерү була. «Дин вә мәгыйшәт»нең фәтва бүлеге мөстафти (фәтва сораучылар) һәм фәтва сораучылар җәмгыяте төзергә тырышу, аларны кайгыртуны арттыру һәм аны дөньяга чыгару омтылышы була. Шулай басма укучыда диндар шәхес тәрбияләргә тырыша.

Моңарчы үз фикерләрен мәчет, җыелышларда, реформист галимнәргә юлланган хатларында җиткергән традиционалистларга, «Дин вә мәгыйшәт» тәэсир итәрлек мәйдан бирә. Нәкъ менә шушы басма традиционалист галимнәрнең, һәм Идел-Урал, һәм Көнбатыш Себер регионы мөселманнарының фикерләрен чагылдырган төп һәм бердәнбер диярлек платформа була.

---

***Материал «Journal of Economic and Social History of the Orient» журналында бастырылган «The Protectors of Religion and Community: Traditionalist Muslim Scholars of the Volga-Ural Region at the Beginning of the Twentieth Century» мәкаләсеннән алынды.***

**Авторы – Вудро Вильсон исемендәге Халыкара үзәкнең, Пенсильвания университеты Джордж Кеннан исемендәге институтының фәнни хезмәткәре Розалия Гарипова**

***Гүзәл Музаферова тәрҗемәсе***

# «Дин вә Мәгыйшәт» журналына нигез салучы

Мөхәммәтвәли Хөсәенов – дин һәм җәмәгать эшлеклесе, мөгаллим, нәшир. Оренбург өязенең Сеитовский бистәсендә туа. Күренекле татар сәүдәгәре һәм хәйриячесе Габделгани Мөхәммәдгали улы Хөсәеновның улы.

Югары дини белемне Казан өязе Кышкар авылы мәдрәсәсендә ала (хәзерге Арча районы). Шулай ук Бохара, Мәккә һәм Мәдинәдә укый, озак вакыт Төркиядә яши. Кышкар мәдрәсәсендә мөгаллим була. 1899 елның 10 мартында Оренбург губернасы идарәсеннән указ ала, Оренбург шәһәренең беренче җәмигъ мәчетенең икенче имам-хатыйбы һәм мөгаллим итеп билгеләнә. 1908 елның 27 августында, М.М.Әлмәтов хәзрәт вафатыннан соң, рәсми рәвештә мәчетнең беренче мулласы итеп билгеләнә. Әтисе Габделганидән аермалы буларак, Мөхәммәтвәли Хөсәе-нов мөселман җәмгыятендә патриархаль нигезләрне саклау яклы булган.

Аның исеме белән аталган «Вәлия» мәхәллә мәдрәсәсе иске ысул белән укытучы мөгаллимнәр һәм имамнар әзерли торган иң абруйлы үзәкләрнең берсе була. Күп кенә татар мәдрәсәләре 1917 елга кадәр иске ысулны саклыйлар. Монда күренекле татар язучысы, галим, дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов, рухани, җәмәгать эшлеклесе, драматург һәм мөхәррир Галәметдин Ханисламов укый. Галимҗан Ибраһимов һәм аның бертуганы «Вәлия»дә 1898 елның көзендә укый башлый.

1906 елның 5 декабрендә Мөхәммәтвәли Хөсәенов басмаханә ача. Анда үз акчаларына гомуми тиражы 175 750 данә булган 104 исемдә татарча дини һәм дөньяви китап (шулар арасында 40 тан артыгы – дини характердагы) чыгара.

1906 елның 31 нче декабреннән 1918 елның февраленә кадәр басмаханәдә дини, сәяси һәм әдәби эчтәлекле «Дин вә мәгыйшәт» журналы чыгып килә.

Мөхәммәтвәли Хөсәенов бик тә үзенчәлекле, каршылыклы шәхес була. Ул эшмәкәрлек белән дә актив шөгыльләнә; «Хусаинов и Ко» сәүдә йортының иганәчесе, зур тары эшкәртү пар тегермәне, терлек сую бинасы, әчегеләр эшкәртү заводы хуҗасы да була; ит, чимал, кәҗүл, йон, ашлык һәм он белән сәүдә итә. Совет хакимияте елларында репрессияләргә дучар ителә, кулга алына һәм 1938 елда Троицк шәһәре төрмәсендә вафат була.

# Журналның беренче мөхәррире турында нәрсәләр билгеле?

«Дин вә Мәгыйшәт»нең беренче мөхәррирләреннән булган Ханисламов Галләметдин Хөснетдин улы 1875 елда Самара губернасының Югары Узовка авылында туа. Оренбург шәһәренең 1 нче җәмигъ мәчете каршындагы мәдрәсәне тәмамлый. Шул ук мәчеттә имам булып тора, 1919 елдан мәдрәсәдә мөгаллимлек эшен башлый. 1907–1919 елларда «Дин вә Мәгыйшәт» журналының мөхәррире булып эшли.

1928 елда Оренбургда дини мәктәп оештырганы өчен гаепләнеп, кулга алына. 1932 елдан Уфа шәһәрендә яши. М. Гатауллин, М. М. Камалетдинов кебек шәхесләр белән таныш була.

1936 елда Габдрахман Ризаэтдин улы Фәхретдинов мөфти урынбасары Кәшәф Тәрҗеманов һәм башка шәхесләрнең контрреволюцион эшчәнлеге турында хәбәрдар булуында, шушы эшчәнлек турында НКВД органнарына хәбәр итмәвендә гаепләнә. 1936 елның 17 июлендә аның белән бергә тагы 12 кеше кулга алына. Алар арасында Ханисламов Галләметдин Хөснетдин улы да була. Шул ук елны ул репрессияләнә. Аның 1938 елдан соң тоткынлыкта вафат булуы билгеле.

1956 елның 21 декабрь карары белән аклана.

# «Вәлия» мәдрәсәсе тарихы

1799 елда Габдессәләм хәзрәт Габдрахимов беренче санлы җәмигъ мәчете каршында Оренбург шәһәренең беренче мөселман уку йорты булган «Вәлия» мәдрәсәсен ача. Оренбург җәмигъ мәчете төзелеп бетеп, 1805 елда Г. Габдрахимов аның ахуны итеп билгеләнгәннән соң, ул мәхәллә мәдрәсәсе булып санала башлый.

1849 елда, бохаралы Тляумбай Маркибаев бүләк иткән җирдә мәдрәсәнең таш бинасы төзелә. Ә 1872 елда бохаралы Фәхретдин Мөэминҗанов биргән җирдә икенче уку корпусы төзелә. 1887 елда Оренбург сәүдәгәре Чемир Акылбаев тагы бер җир бирә, һәм уку-укыту комплексы яңадан төзелә.

Мәктәп бер катлы таш бинаның ике бүлмәсендә урнашкан була, ике катлы таш бинаның өске дүрт бүлмәсендә мәдрәсә, ә аскы дүрт бүлмәсендә аш бүлмәсе, чолан һәм өстәмә уку бүлмәләре була.

Мәдрәсәнең чәчәк аткан чоры Мөхәммәтвәли Хөсәенов исеме белән бәйле. Ул 1899 елда хәлфә, ә 1907 елда мөдәррис була. Бу чорда мәдрәсә иң абруйлы кадими уку йортларының, мөгаллим һәм имамнарны әзерли торган зур үзәкләрнең берсе булып китә. Уку 10 ел дәвам итә, аларның 5 елы – башлангыч белем алу. Мәктәп программасы үз эченә әлифба, уку, язу, матур язу, гакыйдә, Коръән һәм



■ Оренбург шәһәренең 1804 елда салынган 1 нче җәмигъ мәчете XIX йөз ахыры – XX йөз башы фоторәсеме (бина көчле янгыннан соң төзәтелгән рәвешендә)

тәҗвид, Ислам тарихы, хәдисләр, арифметика һәм җәгърафияне ала. Мәдрәсә программасына сарф, нәһү, әхлак, кәләм, тәфсир, хәдисләр, фикһ, фәраиз, мантыйк, арифметика кебек фәннәр керә.

1910–1911 уку елында уку йортларында 140 шәкерт укыган: 70 мәктәп шәкерте һәм 70 мәдрәсә шәкерте. Мөгаллимнәр барлыгы өчәү була. Уку өчен шәкертләр ел саен бары 1 сум түли. Шушы ук вакытта уку йортларының гомуми чыгымнары 1000 сумга якын була. Алар мәхәллә иганәчеләре акчасыннан түләнелә.

1914–1915 елгы мәгълүматларга караганда, мәдрәсәнең бишьеллык уку программасы түбәндәге дәресләрдән гыйбарәт була: беренче ел – әлифба, гыйлме хәл, арифметика, язу; икенче ел – уку, Коръән, арифметика, әйтеп яздыру, хәдисләр, гакыйдә; өченче ел – уку, Коръән, тәҗвид, гакыйдә, арифметика, әйтеп яздыру, матур язу; дүртенче ел – Коръән, тәҗвид, Ислам тарихы, гакыйдә, җәгърафия, арифметика, әйтеп яздыру, хәдисләр, матур язу; бишенче ел – Коръән, Ислам тарихы, гакыйдә, җәгърафия, арифметика, әйтеп яздыру, хәдисләр, матур язу.

1920 елларда «Вәлия» кысаларында җидееллык дини мәктәп эшләп килә, тик 1928 елда аны ябалар, ә оештыручыларын кулга алалар.

1898–1905 елларда «Вәлия» мәдрәсәсендә күренекле татар язучысы Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов (1887–1938) укый. 1905 елгы инкыйлаб дулкыннары тәэсирендә шәкертләр, иске тәртипләргә риза булмыйча, баш күтәрәләр. Шушы чараларда катнашканы өчен, Галимҗан Ибраһимов мәдрәсәдән куыла. Бу вакыйга язучының беренче әсәре, «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907) хикәясендә чагылыш таба, дип фаразлана. «Вәлия» мәдрәсәсен публицист, дини-дидактик характердагы пьесалар авторы, «Дин вә мәгыйшәт» журналының мөхәррире Галәметдин Хөснетдин улы Ханисламов тәмамлый.

**Рәмзилә Шафикова**

# Казан губернасында муллалар ничек

## 2012 ел 2 ноябрь №18 «Дин вә Мәгыйшәт» газетасыннан

**Әлеге мәкаләдә сүз XIX гасыр ахыры – XX йөз башында Казан губернасындагы татар муллаларының мәхәллә халкы белән үзара мөнәсәбәтләре турында барачак.**

Казан губернасында муллалар татар җәмгыятенең, халыкның иҗтимагый-сәяси, икътисади, мәдәни тормышында мөһим социаль роль уйнаган алдынгы катламы булган. Алар җәмгыять алдында мөһим эшләр башкарганнар. Мәчеттә дини гыйбадәтләрне җитәкләү, төрле дини йолаларны башкару, гаилә-никах мөнәсәбәтләрен көйләү, граждан актларын теркәү, мирас бүлү, төрле белешмәләр төзеп бирү, мәхәлләдәге балаларны укыту, әдәп-әхлакны күзәтеп тору, миссионерлык эше, мәхәллә халкына хөкүмәтнең мөһим фәрманнарын, күрсәтмәләрен җиткерү һ. б. бик күп эшләр алар өстендә булган.

Дин эшлеклеләренең җәмгыятьтәге эшчәнлеге халыкның яшәешенә зур йогынты ясаган. Тормышның бар мөһим моментларында да халык үзенең муллаларына мөрәҗәгать иткән. Муллалар дингә хезмәт итеп, гаделлек һәм гыйлемлекне пропагандалап кына калмаганнар, ә үз халкының рухи лидерлары булып мәдәниятне һәм традицияләрне саклаганнар. Мәсәлән, билгеле этнограф Я. Д. Коблов болай дип яза: «Мәхәлләдәге халык мулланы олылап һәм хөрмәт итеп кенә калмый, ә билгеле бер дәрәҗәдә курка да. Шундый күренешне күз алдына китерик. Урамда яшьләр төркеме төрле уеннар белән күңел ача. Беркем белән дә тыелмаган бу яшь кешеләр, үзләрен артык иркен тоталар, кычкырышалар, җыртавышлап өзелеп тормый. Бу күңел ачуның азагы булмас кебек тоела. Һәм менә, мулла өеннән чыга. Ашыкмый гына, ул үзенең җитди һәм олпат кыяфәте белән урам буенча бара. Урамдагы бу тавыш-кычкырышның бетүенә аның менә шул бер күренүе дә җитә. Бу яшьләрнең бар шаяннары, бар шуклары, һәм дә иң кыюлары да, кем кая туры килә, шунда качып бетәләр. Гомумән, мөселман җәмгыятендә ныклы дисциплина саклана, ул дисциплина аларда кече вакытларында ук, гаилә һәм мәктәпләрдә тәрбияләнә».

Һәрбер мулла үз мәхәлләсендәге халыкның әхлакый тәртибен ныклап күзәтеп торырга, җәмгыятьтә бозыклыкка китерүче бар күренешләрне дә тамырында ук юк итәргә тырышырга тиеш дип каралган. Әйтик, муллалар аеруча үз мәхәлләләрендә эчкечелек белән нык көрәшәләр. Диннең спиртлы һәм башка исерткеч эчемлекләрне тыюына да карамасан, кайбер татарлар, аеруча шәһәрдәге эшче сыйныфтагы һәм рус авыллары янында урнашкан авылларда яшәгән татарлар, еш кына качып-посып эчкәли торган булганнар. Әгәр дә, мәхәлләдә эчеп алган берәрсен күрсәләр, аны шунда ук тотып алып муллага алып килгәннәр. Ә мулла исә, бер дә көчен кызганмый, аны таягы белән тукмый торган булган. Базарлы авылда – Әтнәдә, муллаларның таләбе белән, бу кибетләрдән аз булмаган табыш алучы аларның хуҗаларының нык каршы килүенә дә карамастан, шәраб һәм сыра сату кибетләре ябыла. Ә бу авылга базар көннәрендә татарлар гына түгел, руслар да килгән.

Муллаларны үз вазыйфаларын тырышып башкарганнары өчен берәү дә гаепләмәгән. Киресенчә, мондый гамәлләрне халык нык хуплый торган булган. Я. Д. Коблов язуынча, «мулла ниндидер тәртип бозучыны яки җинаять кылучыны, мәсәлән, аракы эчүчене яки урлашып тотылучыны, җәзага тарта башлавы гына була, законның изгелегенә тырышлык куючы башкалар, аның бу эшен дәвам да итеп, төгәлләп тә куя торган булганнар. Мөселман авылында исерек кешене очратуы кыен булуы шуңа күрә бер дә гаҗәп хәл түгел».

Рухи яктан мулла мәхәлләнең башка мөселманнарыннан артык аерылып тормаган. Әлбәттә, дин тәгълиматын яхшырак белгән, әмма аның сүз һәм фикерләре, башкалар белән бер үк төрле белем һәм тәрбия алулары мәхәлләнең башка кешеләренеке кебек үк булган. Мәхәлләдәге мөселман кыскача рәвештә иман нигезләрен белгән, ә мулла исә – аны җентекләп өйрәнгән. Алар арасындагы бар аерма шунда. Мәнфәгатьләрнең, ышануларның, карашларның берлеге муллалы мәхәллә халкы белән берләштергән. Мәхәлләгә җитәкче мулла, күпчелек очракларда, ул мәхәллә белән үзе теләгән юнәлештә җитәкчелек итә алган. Мулланы алдау яки нәрсәне дә булса аннан яшереп алып калу – кыен эш булган. Ул мәхәллә халкының бар гамәлләрен генә түгел, әүй-фикерләрен дә белеп торган, чөнки, ул да алар яшәгән проблемалар белән яшәгән, һәм шуңа да аларга тиешле йогынты ясый алган. Ә икенче яктан, халык муллага чит кеше итеп карамаган, һәм дә аның абруена карусыз буйсынган. Бу җәһәттән, татар муллалары, рус православ дин әһелләре белән чагыштырган вакытта, шактый өстенлеккә ия. Шул ук вакытта, мулланың һәр адымы, һәр әйткән сүзе, аның бар танышлары мәхәллә мөселманнарына билгеле булган. Дин кагыйдәләрен яки традицион йолаларны бозу дип исәпләнгән гамәлләре ачыкланган муллага бер дә җиңелгә туры килмәгән. Мулла, алар фикеренчә, дин һәм закон вәкиле. Һәм шуңа да, ул калганнарга үрнәк булырга һәм үз вазыйфасы биеклегендә торырга тиеш булган, дип яза Я. Коблов.

Имам үз вазыйфаларын тиешенчә башкармаса, яки, үзенең җәмгыятьтәге югары статусын дискредитацияләсә, мәхәллә мөселманнары бу дин әһелен вазыйфаларыннан азат итеп, икенчесен сайлап куярга хокуклы булганнар.

Мулла белән мәхәллә халкы арасында урнашкан конструктив диалог, күп кенә авыр хәлләрдән чыгарга, җәмгыятьнең мөһим проблемаларын хәл итәргә мөмкинлек биргән.

Тормышта авылдашлары муллага, гаилә мәсьәләләре буенча гына түгел, ә башка бәхәсле мәсьәләләр буенча да, мәсәлән, урлашкан өчен, саулыкка зыян китергән өчен гаепләнүчегә җәза билгеләргә һәм башка проблемаларны чишәр өчен дә мөрәҗәгать иткәннәр. Татар авылында мәхкамә шулай барган. Зыян күрүче булган хәл турында авыл старостасы белән муллага хәбәр иткән. Аннан соң староста җыелыш көне билгеләгән, халыкны үткәрелә торган чара белән таныштырган һәм җыелышта карала торган эшне алып бару өчен мулланы чакырган. Хөкем чыгарган вакытта мулла гади хокук нормаларына һәм шәригать кануннарына таянган. Җибәрелгән гаеп эшләр өчен еш кына тән җәзасы кулланылган, аны мулла сайлап алган авыл кешеләре башкарган. Җәза бирү, гадәттә шунда ук, күп халык җыелган урында башкарылган.

Дин әһелләре халыкның әхлак тәртибен аеруча күзәтеп торганнар. Мәсәлән, шәригать азарт уеннар уйнауны тыйган. Әгәр кемнең дә булса азарт уеннар уйнавын белсәләр, аны муллага алып барганнар, мулла аңа үгет-нәсыйхәт биргән. Әгәр дә инде бу кеше бу гаеп эше белән тагын бер тапкыр тотылган икән, аны я чыбык белән сугып җәзага тартканнар, я өч көнгә кулга алып, ябып торганнар. 1875 елны Диния нәзарәте «Бар муллаларга да үз мәхәлләләрендәге кешеләрне тән һәм башка төрле җәзаларга тарту һәм, гомумән, үзләренә үзләре өчен хас булмаган хөкемдарлар ролен алу катгый тыела», – дип фәрман чыгара.



■ «Хөсәения» мәдрәсәсе идарәчеләре һәм имтиханда катнашкан казыйлар

# яшәгән?

Мәчетләр җәмәгать намазлары урыны булганлыктан, аларга тиешле дәрәҗәдә игътибар күрсәтелергә, хөрмәт ителергә һәм тәртиптә тотылырга тиеш булганнар. Шуның өчен муллалар авыл халкын аларны тәртиптә тотарга җитәрлек дәрәҗәдәге акчалар табарга күндергәннәр. Ә мәчетләрне тоту өчен шактый гына эшләр башкарырга кирәк: вакытында ремонт ясарга, мәчетне җылыту өчен җитәрлек дәрәҗәдә утын әзерләп куярга, яктырту өчен шәм һәм керосин запаслары булдырырга, мич һәм төтен чыгару морҗаларын төзек хәлдә тотарга һ. б.

Мөселман дин эшлеклеләренең матди яктан яхшы тәэмин ителгән булуы, аларның үз хезмәтләрен башкаруларында һәм халык белән мөнәсәбәтләрендә мөһим аспект булган. Керемнәренең төп чыганагы – халыктан җыелган иганәләр. Алар акчалата продуктлар, башка әйберләр бирү формасында да булган яки халык үзе килеп эшләп тә ярдәм иткән. Үз хуҗалыклары да (игенчелек, терлекчелек, бакчачылык), төрле һөнәрчелек (умартачылык, табиблык, кием тегү һ. б.) һәм сәүдә дә дин эшлекләренең керемнең шактый өлешен тәшкил иткән. Нигездә, алар халыктан әллә ни аерылып тормаганнар, ләкин татар мәхәлләләрендә үзләренә йөкләнгән мөһим социаль вазифалар башкарулары һәм үз шәхси керемнәре – аларны җәмгыятьтә башкалардан аерып күрсәткән һәм материал яктан тәэмин ителгәннәр рәтенә куйган.

Мөселман дин эшлекләренең халык белән мөнәсәбәтләре арасында тагын бер мөһим аспектлардан суфичылыкны – тәсаувыфны билгеләп китәргә кирәк. Күпчелек татар муллалары тарикатьтә булганнар яки билгеле шәех-ишаннарның укучылары (дини дәвамчылары) булып торганнар. XX йөзгә кадәр бар татар мөфтиләре дә билгеле шәехләрнең мөридләре булганнар. Бу – очраклы хәл түгел: тәсаувыфта тәрбия алу – татар дин эшлеклесе булып китү өчен зарури элемент булып саналган. Ул вакытларда җәмгыятьтә югары баскычта тору, дин өлкәсендә яңа идеяләр тәкъдим итү, ә кайвакытта исә карьера баскычы буенча югарырак күтәрелү дә Идел буе мөселманнарында, шул ук вакытта Урта Азиядә дә суфичылык тарафдары булу-булмауга бәйле булган булырга мөмкин дип әйтергә була. Татар ишаннарының эшчәнлеге, исламның, гыйлемлелекнең, укымышлылыкның тагын да киңрәк таралуына, халыкның тәрбияле булуын арттырырга ярдәм иткән, татар милли яңарышына күп өлеш керткән. XIX гасыр азагы – XX гасыр башы татар муллаларын һәм галимнәрен җәдитчеләр (реформалар тарафдарлары) һәм кадимчеләргә (реформаларга каршы булучылар) бүлгән вакытта, без, бары тик кадимчеләр генә суфичылык тарафдарлары булган дип әйтә алмыйбыз. Җәдитчелекнең күп кенә вәкилләре нәкышбәнди мөридләре һәм ишаннары булган. Ул чорларның рәсми дини эшлеклелеккә карата оппозициядә торучы дип исәпләнүче бар татар мәгърифәтчеләре һәм фикер ияләре дә нәкышбәндия тарикате белән мөнәсәбәттә торганнар.

XIX гасыр һәм XX гасыр башларында Идел-Урал төбәгендә бер үк вакытта мәхәллә муллалары, мәдрәсә җитәкчеләре вазифаларын да башкаручы җәмгыятьтә зур дәрәҗәгә ия бик күп суфи шәехләре яшәгән. Шулар арасында: Хәбибулла Оруви, Гали Түнтәри, Алишевлар династиясе (Кизләү ишаннары), Тукаевлар (Эстәрлебаш ишаннары), Закир ишан Әл-Чистави (Мөхәммәдзакир Камалов), Зәйнулла ишан Расүли, Галимҗан Баруди, Әхмәд Кизләви, Мәхмүд Кизләви, Хәсәнҗан Кизләви, Фәхретдин Нурлати, Нургали Хәсән Әл-Буави, Шәрәфетдин Суксуви, Габдуллатиф бине Яһүдә, Әхмәдсафа бине Габбас, Әхмәдлатыйф бине Габдуллатыйф, Мөхәммәд бине Мөхәммәдхәсән Әл-Урмати, Нуретдин бине Мифтахетдин, Шаһиәхмәд бине Габбас, Мөхәммәдхафиз Әл-Казани, Мөхәммәд Шакир (Сембер), Хәйрулла Алмати һәм башка бик күпләр. Табигый, мәхәллә мәчетенең җитәкчесе шәех яки ишан булса, аның халыкка булган йогынтысы да күпкә зуррак һәм абруйлырак саналган.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк XIX гасыр ахыры – XX йөз башында татар муллаларының мәхәлләләрдә дини-әхлакый йогынтысы гаять зур булган. Бу мулланың шәхси рухи сыйфатларына, интеллектуаль сәләтләренә, аның тәртибенә, тормыш алып бару рәвешенә бәйле. Әгәр дә мулла үз вазифаларын тырышып үтәсә, үрнәк тормыш алып барса, мәчеткә төгәл вакытта, намазларны калдырмыйча йөрсә, мәхәллә халкының тәртибен игътибар белән карап торса, аларны гаепле эшләре өчен гадел хөкем итсә, гомумән, мөселманнар һәм граждannар законнарын саклауда тиешле хезмәт һәм тырышлык күрсәтсә, ул мәхәллә халкы алдында зур абруйга ия булган һәм мәхәлләнең социаль-мәдәни тормышында барысы тарафыннан да танылган җитәкче булып исәпләнгән. Юкка гына халкыбыз: «Мулласы нинди, мәхәлләсе шундый», – димәгән бит.

**Рәшид Маликов,**
**тарих фәннәре кандидаты,**
**Буа мәдрәсәсе мөдире**

# XVII гасырдагы татар мәдрәсәләре

**2012 ел 20 гыйнвар №3 «Дин вә мәгыйшәт» газетасыннан**

Татар халкының йөзләрчә еллар буе мәктәп-мәдрәсәләре булып, алар гасырлар буена татар халкын агартып килгән. Мәгълүм ки, җәмгыятьтәге үзгәрешләр халкыбыз тормышында азмы-күпме тискәре йогынты ясаган: китапларыбыз, мәдрәсәләр, зиратлар, изге урыннар юк ителгән.

Шулай итеп, мирасыбызның күп өлеше югалган. Ләкин тырышканда кайбер фактларны, вакыйгаларны ачыкларга мөмкин әле. Соңгы елларда Истанбулның «Тупкапы» сарае китапханәсендәге кульязмалар арасында татарларның башкаласы булган Сарай шәһәрендә 1290-1395 еллар арасында «Ногмания» исемле мәдрәсә булып, анда кучерелгән кульязмалар саклануы ачыкланды.

Казан ханлыгы башкаласында да Колшәриф (Кол Мөхәммәдшәриф) тарафыннан ачылган мәдрәсә булып, аның шәкертләре 1552 елның 2 октябрендә остазлары белән бергә шәһит киткән.

XVI-XVIII гасырларда татар мөселманнарының, мәчетләре белән бергә, мәктәп-мәдрәсәләре дә җимерелүен безгә онытмаска кирәк. Кызганыч, хәзер дә татарча белем алу системасы юкка чыгарыла бара.

XVII гасырның икенче яртысына татар халкы 1552–1584 еллардагы азатлык сугышында алган яралардан өлешчә аякка баса башлый.

Шул вакытлардан татар мәдрәсәләре ачылу хакында хәбәрләр саклана. Мәсәлән, Казан арты авыллары Алатта, Симеттә; Минзәлә ягындагы Шыгайда; Касыйм ягындагы Әҗедә татар мәдрәсәләре булуга бәйле язма чыганакларны хәзергә ачыклый алдык; билгеле, аларның исемлеге болар белән генә чикләнмидер.

Халкыбызга аң-белем бирергә, аңа телләр үзләштерергә, китаплар укырга өйрәтүдә әлеге мәдрәсәләрнең әһәмияте биниһая зур булган.

Бу урында без аларның беренчесе – Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети исемле галим тарафыннан Симет авылында (Саба районы) ачылган мәдрәсә хакында сүз алып барырбыз. Фәнни әдәбиятта бу кешене Мортаза хафиз (абыз), Мортаза Симети исемнәре белән беләләр.

Аның кайсы елларда тууы һәм вафат булуы хакында төгәл мәгълүмат юк. Ләкин аның 1724 елда исән булуына Ризаэддин бине Фәхреддин бер мәгълүмат китерә.

XVII гасырның соңгы чирегендә Мортаза Симети ачкан мәдрәсәдә белем алган кешеләрнең XVIII гасырның беренче чирегендә галим, шагыйрь, педагог булып танылуы мәгълүм. Алар арасында Рәфикъ бине Таиб Курсави (Курсадан), Габдессәлам бине Урай (Олы Мәңгәрдән), Мансур бине Әнәс Борындыкый (Борындыктан), Әлмөхәммәд бине Сүкәй Шәмәки (16??-1742, август), Әгъзам Тенеки (Тенекидән), Габдеррәшид бине Кадермөхәммәд әс-Сабавый һ. б. булган.

Бу шәхесләрнең остазлары Мортаза Симети – хаҗга барган кеше, аның хаҗга бару сәяхәтнамәсе дә сакланган. Ул үзе Казан ханлыгында, Ибраһим хан заманында аннан тарханлык ярлыгы алган атаклы бер нәселдән. Казан артында, Кама, Зәй, Кенәле буйларында бу нәселнең нәсел тармаклары киң таралган. Мортаза Симети чама белән 1640 елларда туган була. Аның эшчәнлеге һәм ул ачкан мәдрәсәне тәмамлаган шәкертләр XVIII йөзнең өченче чирегенә хәтле татар мәгърифәте үсешенә зур өлеш кертә. Алар арасында иң танылган вәкил Мансур бине Әнәс Борындыкый була. Ул – шагыйрь, дәреслекләр авторы, нык иманлы имам булып, үз мәхәлләсе халкын көчләп чукындырудан саклап кала. Аның тарафыннан язылган «Гавамил китабы» (1727) татар мәдрәсә-ләрендә күп еллар буе гарәп теле дәреслеге буларак кулланылган. Соңгы елларда М. Борындыкыйның бер тарихи кульязмасы да табылды. Ул кульязмада Чыңгыз нәселеннән булган татар ханнары тарихына кагылышлы хәбәрләр язылган.

Мәдрәсәнең хәзерге Рязань өлкәсе Ермишино төбәге Әҗе авылында 1673 елда Тимергали Сафаров тарафыннан нигезләнүе турында язма мәгълүмат сакланган.

1698 елда Шыгай авылы мәдрәсәсен тәмамлап чыккан имам Мөхәммәдшәриф бине Сөләйман хәзрәт мәгълүм. Димәк, Шыгай авылында да мәдрәсә булуына дәлил бар.

Мортаза Симети шәкертләреннән Рафикъ Курсави нәселләре хәзерге Татарстанның Арча, Балтач, Саба, Теләче төбәкләрендәге авылларда күп мәдрәсәләр тоткан имамнар булып торган.

Габдессәлам бине Урай – шагыйрь, Ташкичә мәдрәсәсендә мөдәррис булган. Анда хәтта атаклы Батырша (1711–1755) хәзрәт тә укыган.

Әгъзам Тенеки 1733 елда исән булган. Ризаэддин Фәхреддин аның кыска төннәрдә ястү намазын уку шартлары турында язган китабы булу хакында хәбәр итә.

Гомумән алганда, Мортаза Симети мәдрәсәсе һәм шәкертләре мәгърифәтне һәм мәдәниятне күтәрүдә татар халкы тарихында якты эз калдырган.

**Марсель Әхмәтҗанов,**
**филология фәннәре докторы,**
**Татарстанның атказанган фән эшлеклесе**

# 2017 ел «Галимҗан Баруди елы» дип игълан ителде

Ай башында Казанда Диния нәзрәтенең 2017 елдагы беренче президиум һәм пленар утырышы булды. Җыелыш Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә барды һәм мөфтинең урынбасарлары, нәзарәтнең голәмәләр һәм казыйлар шуралары әгъзалары, республиканың барлык районнары имам-мөхтәсибләре катнашында үтте. Пленумда 2017 елга планнар барланды һәм корылтайга кагылышлы сораулар каралды.

Мөфти хәзрәтләре агымдагы елда дини өлкәдә башкарылачак кайбер вакыйгаларда тукталды. Аерым алганда, зур һәм тарихи вакыйга – Болгар ислам академиясен ачу. «Анда эшләргә яңа коллектив туплана. Кемнәргәдер Болгарга күчәргә дә туры киләчәк. Яңа дөньякүләм дини мәгариф үзәген оештыру өчен Казан белән Болгар арасын шактый таптыйсы була. Бу тарихи идеяне тормышка ашыру җиңел түгел. Әмма Болгарга барырга ерак, дип утыра алмыйбыз. Хәтта укучы булып та без академияне эшләтеп җибәрергә өлеш кертә алабыз», – диде мөфти хәзрәтләре.

Пленум җыелышында Камил хәзрәт Сәмигуллин 2017 елны «Галимҗан Баруди елы» дип игълан итү тәкъдиме белән чыкты һәм ул бертавыштан хупланды.

«Быел татар дин әһеле, мөфти Галимҗан Барудиның тууына февраль аенда 160 ел тула. Галимҗан Баруди кебек танылган дин әһелләрен белергә, аларның китапларын укырга бу юбилей үзе бер сәбәп. Шуның өчен дә бу елны «Галимҗан Баруди елы» дип үткәрергә тәкъдим итәм һәм рухи мирасыбызны өйрәнергә чакырам», – дип билгеләде Камил хәзрәт.

Пленар утырышта голәмәләр һәм казыйлар шуралары хисаплары һәм тәкъдимнәре, мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, нәзарәтнең юридик бүлек җитәкчесе Айрат Билаловның чыгышлары тыңланылды.

# Сүриягә эшлекле сәфәр



Декабрь ахырында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Сүрия Гарәп Республикасының вакыфлар министрлыгы чакыруы буенча Димәшкъ шәһәренә эшлекле сәфәр кылды.

Сәфәр кысаларында кунаклар Димәшкъ ислам университеты һәм танылган «Әбү Нур» университетларында булды, биредәге җитәкчелек, мөгаллимнәр һәм шәкертләр белән аралашты. Мөмкинлектән файдаланып, дин әһелләре 2013 елда фаҗигале төстә вафат булган олуг галим Мөхәммәд Сәет Рамазан Әл-Бутый каберен зиярәт иттеләр һәм рухына дога кылдылар.

Сәфәр вакытында Камил хәзрәт Сүрия галимнәрен Казанда бастырылган Кәлам Шәриф белән дә таныштырды. Киләчәктә галимнәр басмага үз бәяләмәләрен бирерләр, дип көтелә.

Дини гыйлем бирү, Болгар ислам академиясенең уку-укыту программасы турында да фикер алышу булды. «Әл-Фәтх» университеты мөгаллимнәре мөфти Камил хәзрәткә үз укыту программаларын, дәреслекләр исемлекләрен тәкъдим итте.

«Әңгәмә вакытында күренекле руханиларыбызның берсе – Шиһабетдин Мәрҗани турында сүз башлагач, «Әл-Фәтх» университеты ректоры безгә китап киштәсеннән галимебезнең усуль әл-фикһ буенча китабын алып күрсәтте. Сүрияле галимнәр татар руханиларының хезмәтләре белән яхшы таныш. Безнең уртак якларыбыз күп», – дип билгеләде Камил хәзрәт Сәмигуллин.

# Диния нәзарәтенә сайлаулар

**Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең 2017 елның 11 гыйнварында узган чираттагы Пленум утырышында 1 нче санлы беркетмәгә нигезләнеп, Татарстан Республикасы мөфтие, мөфтинең беренче урынбасары һәм Татарстан Республикасы Баш казые вызыйфаларына кандидатлар тәкъдим итүгә карата Пленум әгъзалары тарафыннан тавыш бирү юлы белән таләпләр билгеләнде.**



Мөфти вазыйфасына дәгъва кылучы кандидат утырыш беркетмәсенә нигезләнеп, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенә кергән Җирле мөселман дини оешмасының Мөхтәсибәт җыелышы тарафыннан тәкъдим ителә.

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Уставының 7.2 маддәсе нигезендә, мөфти вазыйфасына дәгъва кылучы кандидат дини һәм дөньяви белемгә ия булырга, мөфти вазыйфасына дәгъва кылу процедурасына кадәр тук-таусыз 5 ел дәвамында дини өлкәдә җитәкче вазыйфаларын башкарган, хөкемгә тартылмаган, намуслы һәм вөҗданлы, сәяси партияләрдә тормаган, намусын шик астына куярга сәбәп булырлык элемтәләргә һәм гаеп итәрлек гамәлләргә ия булмаска тиеш.

Мөфти, мөфтинең беренче урынбасары һәм баш казый вазыйфасына дәгъва кылучы кандидатларга куелган таләпләр, оештыру комитетына алып килергә тиешле документлар белән тулырак **dumrt.ru** сайтында та-нышырга мөмкин.

Документлар кабул итү буенча оештыру комитетының эш графигы: 2017 елның 13 гыйнварыннан 13 февральгә кадәр дүшәмбедән алып җомгага кадәр 9 сәгать 30 минуттан 11 сәгать 30 минутка кадәр һәм 14 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр. Документлар Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт адресы буенча кабул ителә.

# Халык хезмәтчесе Галимҗан хәзрәт Баруди (1857–1921)



Мәшһүр дин галиме, җәмәгать эшлеклесе, күренекле педагог, Үзәк Диния нәзарәтенең мөфтие Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Баруди (Галиев) 1857 елның февраль башында Казан өязенең Кече Кавал авылында (хәзерге Татарстанның Биектау районында) сәүдәгәр гаиләсендә туа. 1860 елда гаилә Казанга күчеп килә. Мөхәм-мәтҗан Галиев ихласлы һәм укымышлы кеше буларак, үз балаларына тиешле белемнәрне бирер өчен малын һәм көчен кызганмый. 1862 елда Галимҗанны Апанай мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Бу мәдрәсә XVIII гасырның 70 нче елларында барлыкка килә һәм Апанай мәчете белән берлектә эшли. Үз чорында бик көчле мәдрәсәләрдән санала. Биредә ул Саләхетдин хәзрәт Исхаковта белем ала, мөстәкыйль рәвештә күп китаплар укый. Тырышлыгы, сәләте зур булу сәбәпле, 1871 елда башлангыч сыйныфларда дәресләр бирә башлый. 1875 елда белемен күтәрү өчен 18 яшьлек Галимҗан Урта Азиягә юл тота. Анда җиде ел укып, дини һәм дөньяви фәннәрне үзләштерә.

1882 елның 15 июнь көнендә яшь галим Казанга күп китаплар һәм кулъязмалар белән кайта. Бу багажның авырлыгы якынча 650 кг, бәясе 5-6 мең була. Галимҗан Баруди гомер буе китап җыю белән шөгыльләнә. 1920 елда Галимҗан Баруди үзенең уникаль китап-ханәсен дәүләткә тапшыра. Бу байлык хәзерге көндә Казан (Идел буе) федераль университе-тының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә саклана.

1882 елның 28 октябрендә Галимҗан хәзрәт Иске татар бистәсенең бишенче җәмигъ мәчетенең (хәзерге Тукай урамындагы Галиев мәчете) имамы итеп билгеләнә. Мәчет каршында дәресләр бирә. Тиздән Галимҗан хәзрәтнең үз мәдрәсәсендә белем бирү мөмкинлеге барлыкка килә. 1882 елда әтисе тарафыннан мәдрәсәнең бер катлы бинасы төзелә. Әлеге мәдрәсәдә Галимҗан Баруди 1883 елда беренче дәресләр бирә башлый. Бу мәдрәсә аңа нигез салган Мөхәммәтҗан исеменә нисбәт ителеп «Мөхәммәдия» исемен ала. Шәкертләрнең саны елдан ел арта бара. Шуңа күрә Мөхәммәтҗан Галиев танылган татар сәүдәгәрләре Әхмәтҗан Сәйдәшев һәм Габдулла Үтәмишев белән мәдрәсәне зурайталар. 1886 елда мәдрәсә бинасының өченче каты салына. Мәдрәсәнең даны киң тарала.

1886 елдда Галимҗан Баруди изге Мәккә шәһәренә хаҗ кылырга бара. Бу сәфәрдә ул Истанбулны, Мисырны зиярәт итә, галимнәр белән очраша, белемнәрен арттыра.

Казанга кайткач, Галимҗан хәзрәт иске иҗек ысулын аваз ысулына алыштыра, уку-укыту программасын камилләштерә, яңа дәреслекләр, китаплар яза. Галимҗан Барудиның беренче китабы «Гильм әт-тәүхид» («Аллаһның берлеге турында гыйлем») 1890 елда басыла. 1891 елда яңа ысул белән укыту өчен «Сәвадхан» («Гыйлем иясе») исемле әлифба төзи. Бу китап яңа ысул белән төркичә язылган беренче әлифба булып санала һәм 1891–1915 елларда унике тапкыр басыла. Шул ук елда аның арифметика буенча «Нәмунәи хисаб», ислам нигезләре буенча «Китаб әс-салават» («Догалар китабы»), «Бәдә әл-мәгариф» («Белемнәрнең нигезе») «Сад пәнд» («Йөз нәсый-хәт») дигән хезмәтләре дөнья күрә.

1901 елда Галимҗан Барудиның зур абруен искә алып, Габдулла Үтәмишев, Әхмәд Хөсәинов һәм башка татар байларының ярдәме белән мәдрсәснең өч катлы таш бинасы салына (хәзерге Тукай урамы, 34а). Мәдрәсә заманча җиһазландырыла, шәкертләр өчен барлык шартлар тудырыла. Мәдрәсәснең ишегалдында ашханә, авырулар өчен хастаханә, итек-читек, кәвеш төзәтү, агач эше, китап төпләү остаханәләре булдырыла.

1906–1908, 1913–1917 елларда Галимҗан Баруди татар телендә «Әд-дин вәл-әдәп» исемле фәнни һәм дини журнал чыгара.

1908 елда Галимҗан хәзрәтне панисламизмда гаепләп, ике елга Вологда губернасына сөргенгә җибәрәләр. Анда 4 ай яшәп, Эчке эшләр министрлыгыннан чыгу өчен рөхсәт ала. Чит илләргә сәяхәт кылып, Вена, Будапешт, Истанбул, Димәшкъ, Бәйрут кебек шәһәрләрдә булып кайта.

Галимҗан Баруди сөргендә булган вакытта, энесе Габдрахман хәзрәтнең ярдәме белән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе эшен дәвам итә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең даны бөтен Россия мөселманнары арасында тарала. Биредә татар яшьләре генә түгел, башкорт, казакъ, кыргыз, кумык һ. б. төрки халык вәкилләре дә гыйлем алырга омтыла. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе 1918 елга кадәр эшләгән.

Галимҗан хәзрәт Баруди Русия мөселманнарының сәяси тормышында да актив катнаша. Ул 1906 елның гыйнвар һәм август айларында узган Русия мөселманнарының 2 нче һәм 3 нче корылтайлары эшендә катнаша. «Иттифак әл-мөслимин» мөселман фиркасе Үзәк комитетының әгъзасы итеп сайлана.

1917 елның май аенда Мәскәүдә I Бөтенрусия мөселман корылтае уза. Күпчелек тавыш белән Русия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте мөфтие итеп Галимҗан Баруди сайлана. Әмма Галимҗан хәзрәт үзе бу турыда Чимкент шәһәрендә булганда белә.

Казанга кайткач, Галимҗан Баруди мөфти вазыйфасы турында туганнары һәм якын кардәшләре белән киңәшә, аларның фикерләрен тыңлап, бу җаваплы вазыйфаны алырга риза була.

Галимҗан хәзрәт мөфти буларак күп хезмәтләр башкара, халыкка армый-талмый хезмәт итә, үлеме дә изге юлда йөргәндә була. Мөфти хәзрәтләре 1921 елның 6 декабрендә Мәскәү каласында ачларга ярдәм күрсәтү эшләре белән командировкага барган чакта вафат була. Аны Казанга кайтаралар һәм Яңа татар бистәсе зиратында дәфен кылалар.

**Нияз хәзрәт Сабиров,**
**ТҖ МДН дәгъвәт бүлеге җитәкчесе,**
**Апанай мәчете имам-хатыйбы,**
**тарих фәннәре кандидаты**



■ «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимнәре һәм иганәчеләре. 1915 ел (фото www.archive.gov.tatarstan.ru сайтыннан алынды)

# Көнчелек хакында

Дин-мөбиндә мөхтәрәм газиз кардәшләрем, ватандашларым, милләттәшләрем! Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт-бәрәкәтләре, һәр ике дөньядагы сәламе җөмләгезгә булса иде.

Пәйгамбәребез ﷺ бер хәдис-шәрифендә: «Көнчелек яхшылыкларны нәкъ ут коры утынны ашаган шикелле ашап барыр», – дигән. Шулай Расүлуллаһ иман әһелләренә көнчелекнең нәрсә икәнлеген ачыклап бирде. Мөселманнарга карап: «Бер-берегездән көнләшмәгез, бер-берегез белән араны өзмәгез, бер-берегезне күрмәс булмагыз, бер-берегезгә дошман булмагыз, Аллаһ бәндәләре буларак, бер-берегезгә кардәш булыгыз!» – дип киңәшнәсыйхәт бирә. «Бер-берегездән көнләшмәгез», – дип, Расүлуллаһ юкка генә әйтмәс. Шушы хәдис-шәрифтәге тыюларга күз салсак, «бер-берегездән көнләшмәгез» дию тик кенә беренче урында тормас. Бер-береңә дошман булу да, бер-берең белән араларны өзү дә, бер-береңне күрмәс-сөймәс булу да – барысы да көнләшү белән бәйле, барысының да асылы, нигезе шул көнчелек белән тоташкан.

Пәйгамбәребез ﷺ әйтә: «Элек тә, бүген дә бөтен бәла-казалар, хәсрәтләр, сугышлар, дошманлашулар, бер туган икенче туганга пычак күтәрүләр шул көнләшү дигән нәрсә белән, хөсетлек белән бәйле булып кала. Үзегезгә элгәрәк булган өммәтләрнең авыруы эләкте: көнчелек һәм куралмаучылык. Бер-береңне куралмау, нәфрәтләнү – пәке белән бердер. Мин чәч кыра торган пәке дип әйтмим, сүзем динне кыра торган пәке турындадыр. Җаным Аның хөкемендә булучы Аллаһы Тәгалә белән ант итәмен, иман китермичә, җәннәткә кермәссез, бер-берегезне якын күрмичә, яратмыйча, иман да китерә алмассыз. Сезгә шуны раслый торган нәрсәнең ни икәнлеген ачыйммы? Бер-берегезгә сәлам әйтегез, сәламләү таратыгыз».

Икенче бер хәдисендә Расүл Әгъзам: «Алдагы өммәтләрнең авыруы сезгә дә тиячәк», – дигән. Шуннан соң янындагы халык: «Йә Расүлуллаһ! Нинди авыру турында сүз бара?» – дип аптырый. Расүлуллаһ: «Тәкәбберлек, масаю, дөньялык өчен мал арттыру, бер-береңбелән узышу, бер-береңнән ераклашу, бер-береңнән көнләшү авыруы. Шундый дәрәҗәгә җитәр ки, хәтта башта бозыклык, аннан соң бер-береңне кыру китәр», – дип, Рәсүлуллаһ бу хәдистә дә авыруларның кайсысы кыруга, фетнәгә, үтерешкә китереп чыгарачак икәнлеген күрсәтә. Янә сүз көнчелек, хөсетләнү турында бара. Коръәнгә күз салыгыз әле! Иблис атабыз Адәм, анабыз Хавага бирелгән дәрәҗәдән көнләште. Нәтиҗәдә, адәм угыллары җәннәткә бик олы сынаулар үтеп кенә, Аллаһы Тәгаләнең илаһи рәхмәте белән генә кире кайтырлар. Барысы да түгел, анысын да онытмыйк! Шуннан Кабил белән Һабил, Адәм атабызның угыллары, көнләшеп, бер туган икенче кан туганын үтереп ташлады. Зәкәрия пәйгамбәр *2*: «Аллаһы Тәгалә: «Көнче – Минем нигъмәтемнең дошманы, тәкъдире белән тарткалашучы, ачуымны чыгаручы, бәндәләремә чыгарган ризык өлеше белән риза булмаучы», – дип әйтте», – дигән. Әйе, кеше башка кешенең малыннан, кыяфәтеннән, дәрәҗәсеннән, өстенлегеннән көнләшсә – Аллаһы Тәгаләнең дошманы булыр. Ни өчен? Һәркемгә ризыкны, дәрәҗәне, саулыкны, кыяфәтне бирүче Аллаһы Тәгалә бер Үзе генә. Димәк, берәүнең саулыгына «авырмый, чирләми, гомере буена сау-сәламәт» дип әйтүләрне исегезгә төшерегез! Икенче бер бәндә көнләшсә, көнче Аллаһы Тәгалә белән тарткалаша булып чыга. Ул кеше саулыкны кайдандыр үзе сатып алмаган бит! Ул саулыкны аңа Ходай Тәгалә биргән бит! Шулай итеп, көнчелек – шайтани авыру, адәм баласының җелегенә үтә. Көнчелек бер аерым кешедә генә түгел, хәтта кабилә, халык, милләт дәрәҗәсенә дә күтәрелә. Күреп торабыз, бүген көнчелек иҗтимагый чиргә, авыруга әйләнеп бара. Малда, акчада, ризыкта берничек тә тигезлек була алмый, чөнки ризык-малны Аллаһы Тәгалә бер Үзе генә, Үзенең илаһи хөкеме-карары белән аерым кешегә, шәхескә бирә. Аллаһы Тәгалә: «Әгәр адәм угылларының ризыклары бертигез булса, алар бер-берсе белән талашып, сугышып бетәрләр иде», – дигән. «Өммәтем өчен иң курыкканымның да куркынычы – алар арасында мал арттырып, берберсеннән көнләшеп, бер-берсен кырып ташлаудыр», – дип Аллаһы Тәгалә хәбибе Мөхәммәд Әл-Мостафаның ﷺ өммәте өчен үзеге өзелгән. «3 төрле нәрсәдән беркем дә котыла алмас», – ди Расүл Әкрам бер хәдистә. Бу сүзләрнең мәгънәсе – «Ул 3 төрле нәрсәнең тәэсире һәркемгә дә тиячәк» дигән сүз. Ул 3 нәрсә, Пәйгамбәребез әйтүенчә, – фараз кылу (ягъни «болай булырмы икән, тегеләй булырмы икән, болай иткән булсам, тегеләй булыр иде…» дию), шомлану һәм хөсетләнү. Шуңа күрә дә, «Фаразласаң – фаразлаганыңны үтәмә, шомлансаң – ул шомлануыңа бирелмә, көнләсәң – көнчелек артыннан иярмә», – дип өйрәтә дә расүлебез Мөхәммәд ﷺ. Шул ук вакытта «сакланганны Ходай саклар» дию дә бик хак. Фаразлама – Аллаһы Тәгаләгә тапшыр, тәвәккәлләү. Шомланма – Аллаһы Тәгаләнең әмеренә буйсын, бер эшкә тотынырга булдыңмы – җитез булып, үлчәп, уйланып тотын. Көнләшсәң, «Йә Раббым! Булган, биргән нигъмәтеңә мең рәхмәт-лемен!» – дип доганы кыл! Берәүгә ярдәм итсәң, иткән ярдәмең турында кычкырма, аны бөтен дөньяга белгертмә!

**Фәрид хәзрәт Сәлман,**
**Коръән Кәрим вә Пакь Сөннәт өйрәнү мәркәзе җитәкчесе**

• СОРАУ-ҖАВАП •





## Хатын-кызга намазны киң чалбар киеп уку дөрес буламы?

Асылда, хатын-кыз чалбары ират кия торган чалбарга охшаш булырга тиеш түгел. Әгәр чалбар киң булса, гәүдәнең үзенчәлеген күрсәтмәс булса, намаз дөрес булыр.

## Эш урынында хатын-кыз намазы

**Сорау:** Эш урынында, эш бүлмәсендә намаз укырга бөтен шартлар бар, әмма анда ят ирләр эшли. Алар Ислам диненә хөрмәт белән карасалар да, намаз укырга каршы булмасалар да, күңел тыныч түгел. Нәрсә эшләргә?

**Җавап:** Әгәр намаз укырга барча шартлар булса, тәһарәт, урын пакьлеге вә башка шартлар үтәлсә, намаз уку дөрес булыр. Әмма ул кешеләр бүлмәдә булмаган вакытта намазны уку хәерлерәк булыр.

**Фәрид хәзрәт Сәлман,**
**Коръән Кәрим вә Пакь Сөннәт өйрәнү мәркәзе җитәкчесе**

# Бала имезү мәсьәләсе

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

**«Аналар балаларын тулы ике ел имезсеннәр! Бу хөкем имезү хакын тулысынча үтәргә теләүче хатыннар өчен. Атага лазем була бала имезүче яки тәрбияләүче хатынны ризык һәм кием белән тәэмин итү шәригать кушканча гаделлек белән. Бер кеше дә көче җитмәгән эш белән йөкләтелмәс, мәгәр көче җиткән белән йөкләтелер. Бала анасына зарар итмәгез баланы сәбәп итеп, һәм атага да зарар итмәгез баланы сәбәп итеп, һәм ата үлеп, аның урынына калган варисны да җәберләмәгез! Әгәр ата-ана, киңәшләшеп, баланы ике яшькә хәтле имезмәскә риза булсалар, ике яше тулмас борын имүдән туктатсалар, икесенә дә гөнаһ булмас. Әгәр балагызны башка хатынга биреп имездерсәгез, сезгә гөнаһ юк, имезүче хатынга тиешле хакын бирсәгез. Аллаһыдан куркыгыз, Аның хөкемнәренә хилафлык кылудан сакланыгыз! Яхшы белегез, Аллаһ сезнең кылган эшләрегезне күреп күзәтүче».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:233



Шәех Мөхәммәд ибн Адәм Әл-Кәүсәри аңлата (фәтва хәнәфи мәзһәбе буенча): «Китерелгән аять балага күкрәк сөтен имезү – ана кешенең әхлакый һәм дини бурычы икәнен белдерә, аны моңа суд аша мәҗбүр итү мөмкин булмаса да. Аллаһы Тәгаләнең: «Аналар балаларын тулы ике ел имезсеннәр», – дигән боерыгы балага ике ел дәвамында күкрәк сөтен имезүнең аның хокукы булуын күрсәтеп тора. Ләкин нигезле сәбәпләр булса (мисал өчен, хатын-кыз каты авырса яки көчсез булса, яки аның сөте балага туры килмәсә, яки ул йөкле булса), ана имезүдән баш тарта ала. Аллаһы Тәгалә: «Әгәр ата-ана, киңәшләшеп, баланы ике яшькә кадәр имезмәскә риза булса, ике яше тулмас борын имүдән туктатсалар, икесенә дә гөнаһ булмас», – дип әйткән. Димәк, әгәр ата-ана киңәшләшеп, баланы күкрәктән аеруны дөресрәк тапсалар, һәм бу балага зыян китермәсә, бу рөхсәт ителә. Әгәр эти-әни балага сөт анасы кирәк дип тапса, бу да тыелмый, чөнки Аллаһы Тәгалә: «Әгәр балагызны башка хатынга биреп имездерсәгез, сезгә гөнаһ юк, имезүче хатынга тиешле хакын бирсәгез», – дип әйткән».

Дөреслектә, хатын-кыз баласын имезә алмаган очраклар шактый аз. Еш кына яшь аналар турыдан-туры сәламәтлегенә карамаган билгеләр буенча, яки сәбәпләрен ачыклап бетермичә, сөтем кимеде дип, баланы катнаш, ә соңрак тулысынча ясалма тукландыруга күчерә. Әгәр эти-әни имезүне туктатырга булса, моның гөнаһы юк, әлбәттә, ләкин бу карарны ашыгып кабул итәргә ярамый. Күкрәк сөтен киметү яки аннан бөтенләй баш тарту гадәти хәл буларак кабул ителергә тиеш түгел. Хатын-кыз авырган очракта да, бүгенге көндә ул имезү вакытында кулланырга рөхсәт ителгән дарулар белән дәвалана ала. Балага әнисенең сөте туры килмәгән очраклар исә бөтенләй сирәк күренеш.

Имезүче аналар турында мондый хәдисләр бар:

Әнәстән ؓ риваять ителә: Сәлама, Пәйгамбәребез ﷺ улы Ибраһимның сөт анасы, әйткән: «Ий Аллаһ Илчесе! Син бар яхшы хәбәрләрне ир-атларга җиткерәсең, ә хатын-кызларга берни хәбәр итмисең». Пәйгамбәребез ﷺ: «Моның турында сорарга ахыйрәтләрең этәрдеме?» – дип сорый. Ул: «Әйе», – дип җавап бирә. Пәйгамбәр ﷺ: «Берегез йөкле булып, ире аннан канәгать булса, ул ураза тоткан һәм намаз, дога кылган кеше кебек савап ала. Аннан соң, баласын тапканда, аның нинди юанычлы бүләкләргә лаек булуы җирдәге бер кешегә дә, күктәгеләргә дә билгеле түгел. Ә баласын тапкач, бер генә тамчы күкрәк сөте дә, баласының бер генә имүе дә түләүсез калмый. Әгәр бала төннәрен аңа йокларга бирмәсә, ул Аллаһ ризалыгы өчен җитмеш колны азат иткән кеше кебек савап ала. Бу сезне сөендермәсме?» – ди.

Шәех Габдуллаһ түбәндәге риваятьнең Әдһәми Әбү Нәгыйм Әл-Әсбаханиның «Хилйә»сендә китерелгәнен әйтә: Сәед ибн Әл-Җөбәер тапшыра: «Мин ибн Гомәрнең ؓ Пәйгамбәребезнең ﷺ (шундый гыйбарәсен) җиткергәненә ышанам: «Көмәнле вакытыннан бала табу вакытына кадәр һәм бала тапкан вакыттыннан имезүдән туктаганчыга кадәр хатын-кыз Аллаһ юлында көрәшүчегә тиң».

Остазлар һәм галимнәр безнең гамәлләребез нигезендә ризык ята, ди. Бала өчен ике яшькә кадәр иң яхшы ризык – ана сөте. Баласын һәр имезүе алдыннан хатын-кызның гыйбадәт кылырга ниятләве яхшы. Бала каршында бурычын үтәп, ул Аллаһ ризалыгын эзләргә тиеш. Мөслимә өчен сабыен файдалы сөте белән тукландыру – иң күркәм шөгыль.

Ясалма катнашмаларга караганда, күкрәк сөте баланың аш кайнату системасы аша ике тапкыр тизрәк үтә. Күкрәк сөтенең ферментлары һәр имезү вакытында кирәкле элементларны максималь дәрәҗәдә үзләштерергә ярдәм итә. Күкрәк сөте балада аллергия булу куркынычын кимետә. Күкрәк сөтенең компонентлары инфекцияләргә каршы торырга ярдәм итә һәм иммунитет оешуга иң кулай шартлар тудыра. Бала үсә барган саен, күкрәк сөтенең составы үзгәреп тора һәм балага яраклашып бара.

Тикшеренүләр күкрәк сөте имеп үскән балаларның фикерләү сәләте югарырак булуын күрсәтә. Имезү ана белән бала арасында ныклы бәйләнеш булдыра, ә Исламда бу бик мөһим.

Пәйгамбәребезнең ﷺ исә сөт аналары өчәү була. Бу күркәм хатыннар: Сувәйбә – Пәйгамбәрнең ﷺ беренче сөт анасы, Хәлимә бинти Әбү Зәйд, анда Пәйгамбәребез ﷺ дүрт яшенә кадәр тәрбияләнгән һәм Бәрәкәт Өмме Әйман.

**Шәех Әмҗәд Рәшит мәкаләсе файдаланылды**

# Мөслимә ир-атка үзе тәкъдим ясый аламы?

Ислам күзлегеннән караганда, мөслиманең мөселман булган ир-атка үзенә өйләнергә тәкъдим итүендә гаеп итәрлек берни юк.

Билгеле булганча, Хәдичә анабыз ؓ Пәйгамбәребезгә ﷺ кияүгә чыгарга теләвен үзе белдергән.

Бу мәсьәләгә караган Әл-Әзһәр университеты профессоры, күренекле галим Гали Җомга фәтвасын китерергә мөмкин: «Шәригать буенча, мөслиманең мөселман булган ир-атка үзенә өйләнергә тәкъдим итүен тыя торган бернинди боерыклар юк. Ләкин ир-атның тышкы кыяфәте, үз-үзен тотышы аркасында алданып калмас өчен, мөслимәгә сак булу матлуб.

Бу очракта хатын-кызга берничә кагыйдәне истә тотарга кирәк. Беренчедән, диндар ир сайларга ярдәм итсен өчен, хатын-кызга тәкъвалы ярдәмчегә, яучыга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Икенчедән, ул ир итеп саф күңелле, булачак гаиләсенең матди хәлен кайгыртырга сәләтле хак мөселманны сайларга тырышырга тиеш.

Хатын-кызга мәхрәм булмаган ир-ат белән, хәтта ул тәкъдим ясарга ниятләгән кеше булса да, ялгыз гына калырга ярамаганын онытмаска кирәк. Бу шарт яучыларның әһәмиятлелеген тагын бер тапкыр ассызыклый».

Ә Аллаһка яхшырак билгеле.

**Islam-Today сайтыннан**

# Яшьләрне «Яшьләр дулкыны» берләштерде

Гыйнвар аеның искиткеч матур көннәрендә Саба җирлегендә «Яшьләр дулкыны» дип исемләнгән мөселман яшьләренең актив яллары узды.

Яшьләр өчен оештырылган чараларның беренчесе Саба Җәмигъ мәчетендәге үткәрелгән түгәрәк өстәл булды. Очрашуда төп спикер буларак район имам-мөхтәсибе Айнур хәзрәт Әхмәтов, Мөслимәләр берлегенең Сабадагы вәкиле Ильмира ханым Галимуллина һәм төп активисткаларының берсе Гүзәл ханым Шәрифуллинада катнаштылар.

Яшьләр Лесхоз бистәсендәге «Нарат» боз сараенда тимер аякта шуулар үткәрде. Иләбәр авылында имам-хатыйб Рушан хәзрәт белән очрашу оештырдылар. Пылау, лагман кебек тәмле ризыкларга мул өстәл артында үткән очрашуга яшьләр дә буш кул белән килмәгән иде. Алар авыл балалары белән бик кызыклы викторина үткәрде.

Әлбәттә, чараларны оештыруда ТР МДНнең Яшьләр бүлеге бик зур өлеш кертте. Мәсәлән, Айгөл Биктимирова бүләкләрнең бер өлешен әзерләүне үз өстенә алды, ә Тимур Истратий мөһим киңәшләрен биреп, оештыру тәҗрибәсе белән уртаклашты. Тынычлык мәчете активисты Артур Фәхретдин алып баручы сәләтләрен эшкә җикте. Кама Тамагы яшьләр вәкиле Кәдрия Гатауллина уеннар һәм викторина сорауларын әзерләүдә ярдәм итте. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре Элина Әбүләесова һәм Әлбинур Каюмова балаларга бүләк әзерләүдә үз өлешләрен керттеләр. Эльвира Вәлиева, Камилә Хәйруллина, Әлфия Гыйрфанутдинова да ярдәм итте. Казан шәһәре Совет районы мөхтәсибәтенә һәм Рөстәм хәзрәт Вәлиуллингa, аның ярдәмчесе Руслан Камаловка һәм мөхтәсибәтнең активисты Ленар Кашаповка бүләкләр алуда үз өлешләрен керткәннәре өчен зур рәхмәтлебез. Шулай ук Арча районыннан Луиза Корбановага, Саба мөселман яшьләре активистлары Зөләйха Нурәхмәтова, Гөлинә Вәлиева, Марат Хуҗин, Алмаз Саматов, Нияз Галимҗанов, Альмир Исмәгыйлев, Фәридә Галимуллиналарга да чараларга әзерләнүдә олы ярдәм күрсәткәннәре өчен рәхмәтләребезне җиткерәбез.

«Яшьләр дулкыны»ның төп максаты булып өммәтебез яшьләрен берләштерү, файдалы һәм актив тормышка өндәү торды. Киләчәктә дә мондый чаралар күп оештырылыр, ин шә Аллаһ!

Аллаһы Тәгалә барчабызга да тыныч тормыш, тулы иман һәм ике дөнья бәхете насыйп кылса иде.

**Алмаз Галимҗанов,**
**Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр эше буенча урынбасары**

## Реклама бүлеге







## КАЗАН ӨЧЕН ФЕВРАЛЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Таң беленә | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.02.2017 | 05:28 | 06:07 | 07:37 | 12:00 | 14:26 | 16:17 | 18:04 |
| 02.02.2017 | 05:27 | 06:05 | 07:35 | 12:00 | 14:28 | 16:19 | 18:06 |
| 03.02.2017 | 05:25 | 06:03 | 07:33 | 12:00 | 14:30 | 16:22 | 18:08 |
| 04.02.2017 | 05:24 | 06:01 | 07:31 | 12:00 | 14:32 | 16:24 | 18:10 |
| 05.02.2017 | 05:22 | 05:59 | 07:29 | 12:00 | 14:34 | 16:26 | 18:12 |
| 06.02.2017 | 05:20 | 05:57 | 07:27 | 12:00 | 14:36 | 16:28 | 18:14 |
| 07.02.2017 | 05:18 | 05:55 | 07:25 | 12:00 | 14:38 | 16:30 | 18:15 |
| 08.02.2017 | 05:17 | 05:53 | 07:23 | 12:00 | 14:40 | 16:32 | 18:17 |
| 09.02.2017 | 05:15 | 05:51 | 07:21 | 12:00 | 14:42 | 16:35 | 18:19 |
| 10.02.2017 | 05:13 | 05:48 | 07:18 | 12:00 | 14:44 | 16:37 | 18:21 |
| 11.02.2017 | 05:11 | 05:46 | 07:16 | 12:00 | 14:46 | 16:39 | 18:23 |
| 12.02.2017 | 05:09 | 05:44 | 07:14 | 12:00 | 14:47 | 16:41 | 18:25 |
| 13.02.2017 | 05:07 | 05:42 | 07:12 | 12:00 | 14:49 | 16:43 | 18:27 |
| 14.02.2017 | 05:05 | 05:40 | 07:10 | 12:00 | 14:51 | 16:45 | 18:29 |
| 15.02.2017 | 05:03 | 05:37 | 07:07 | 12:00 | 14:53 | 16:48 | 18:31 |
| 16.02.2017 | 05:01 | 05:35 | 07:05 | 12:00 | 14:55 | 16:50 | 18:33 |
| 17.02.2017 | 04:59 | 05:33 | 07:03 | 12:00 | 14:57 | 16:52 | 18:35 |
| 18.02.2017 | 04:57 | 05:31 | 07:01 | 12:00 | 14:59 | 16:54 | 18:37 |
| 19.02.2017 | 04:55 | 05:28 | 06:58 | 12:00 | 15:01 | 16:56 | 18:39 |
| 20.02.2017 | 04:53 | 05:26 | 06:56 | 12:00 | 15:03 | 16:58 | 18:41 |
| 21.02.2017 | 04:50 | 05:23 | 06:53 | 12:00 | 15:05 | 17:01 | 18:43 |
| 22.02.2017 | 04:48 | 05:21 | 06:51 | 12:00 | 15:07 | 17:03 | 18:45 |
| 23.02.2017 | 04:46 | 05:19 | 06:49 | 12:00 | 15:09 | 17:05 | 18:47 |
| 24.02.2017 | 04:43 | 05:16 | 06:46 | 12:00 | 15:11 | 17:07 | 18:49 |
| 25.02.2017 | 04:41 | 05:14 | 06:44 | 12:00 | 15:13 | 17:09 | 18:51 |
| 26.02.2017 | 04:39 | 05:11 | 06:41 | 12:00 | 15:15 | 17:11 | 18:53 |
| 27.02.2017 | 04:36 | 05:09 | 06:39 | 12:00 | 15:17 | 17:13 | 18:55 |
| 28.02.2017 | 04:34 | 05:06 | 06:36 | 12:00 | 15:18 | 17:16 | 18:57 |

**ДИН ВӘ Мәгыйшәт**

*Гыйнвар саны, №1 (258)*

Баш мөхәррир: **Сәмигуллин К. И.**
Мөхәррир: **Шафикова Р. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6/27 нче йорт
**Электрон адресы:** ramzilya.shafikova@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 202-07-74

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
**Нияз САБИРОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №3061
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя – 6 сум.
График буенча бу санга 23 нче гыйнвар көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.